**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

29 декабрь 2023 ел № 213

**Әтнә муниципаль районы Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты турында»гы 2022 елның 15 декабрендәге 159 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Әтнә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Ф.И.Гыймадиев докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Әтнә муниципаль район Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Әтнә муниципаль районының бюджеты турында» 2022 елның 15 декабрендәге 159 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. 2023 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 664446,2 мең сум;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 687588,3 мең сум;

в) Әтнә муниципаль районының бюджет дефициты 23142,1 мең сум.»

2) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 1 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 1 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

3) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 2 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 2 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

4) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 3 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 3 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

5) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 4 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 4 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

6) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 5 нче кушымтаның 1 нче таблицасын 5 нче кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

7) Әтнә муниципаль районы Советы карарына 9 нчы кушымтаның 1 нче таблицасын 9 нчы кушымта буенча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әтнә районы Башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарларын расларга:

№ 701 03.10.2023ел.; № 759 27.10.2023ел.; № 767 01.11.2023ел.;
№ 780 13.11.2023ел.; № 807 27.11.2023ел.; № 823 13.12.2023ел.;
№ 834 18.12.2023ел.; № 836 19.12.2023ел.; № 850 28.12.2023ел.

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы www.pravo.tatarstan.ru хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Г.Г. Хәкимов